КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 ноябрь

г.Казань

№ 1476

Капиталь ремонтка кертемнәр исәбеннән тупланган акчаларның максатчан тотылуын тикшереп торуны һәм әлеге акчаларның сакланышын тәэмин итүне гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт кертемнәре исәбеннән җыелган акчаларның максатчан тотылуын һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан әлеге акчаларның сакланышын тәэмин итүне контольдә тоту тәртибе;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт кертемнәре исәбеннән җыелган һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә акчалар күчерү өчен билгеләнгән һәм кредит оешмасында ачылган махсус счеттагы акчаларның максатчан тотылуын һәм әлеге акчаларның сакланышын тәэмин итүне контольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында» 2013 ел, 29 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 гыйнвар, 11 нче, 2022 ел,

19 апрель, 366 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт фонды акчаларын түләү тәртибенең 8 пунктындагы 8.3 пунктчасын  үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин